КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 август г.Казань № 868

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарының аерым нигезләмәләрнең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2022 ел, 6 июнь, 526 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарының аерым нигезләмәләрнең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2022 ел, 6 июнь, 526 нчы карарына, 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Гражданнарга, медицина оешмаларында, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, җәмәгать транспортында, кешеләр күпләп була торган урыннарда, шулай ук, 1,5 метр дистанцияне (социаль дистанцияне) үтәү мөмкинлеге булмаган очракта, гражданнар белән хезмәттәшлектә оешмаларның ябык урыннарында булганда, сулыш органнары индивидуаль яклау чараларын (битлек, респираторлар) кулланырга тәкъдим итәргә.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин